# ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЗӘЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАГРАЖ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ

## КАРАРЫ

**№ 93** **17.07.2023 ел**

**«Җир салымы турында” 2014 елның 14 ноябрендәге 142 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Баграж авыл җирлеге Советы карарына үзгәрешләр кертү хакында**

Россия Федерациясе Салым кодексының31 бүлеге, “Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештурының гомуми принциплары турында” 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон нигезендә, шулай ук Баграж авыл җирлеге Уставына таянып, Зәй муниципаль районының Баграж авыл җирлеге Советы

КАРАР ИТТЕ:

1. “Җир салымы турында” 2014 елның 13 ноябрендәге 142 номерлы Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Баграж авыл җирлеге Советы карарына (2015 елның 14 сентябрендәге 179 номерлы, 2017 елның 25 сентябрендәге 81 номерлы, 2018 елның 12 мартындагы 101 номерлы, 2020 елның 10 ноябрендәге 14 номерлы карарлар редакциясендә) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. 4 пунктны түбәндәге эчтәлекле 4.2.4 пунктчасы белән тулыландырырга:

“4.2.4. “Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Баграж авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге җирле үзидарәсенең башкарма-боеру органы – чикләнмәгән затлар даирәсе тоткарлыксыз файдалана торган гомуми файдаланудагы җир кишәрлекләренә карата”.

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, «Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталы»нда (PRAVO.TATARSTAN.RU) һәм Зәй муниципаль районы сайтының “Авыл җирлекләре” бүлегендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

4. Карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

**Совет рәисе** **П.Н. Минеев**